КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 16 апрель г.Казань № 254

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ел инженеры» республика конкурсын үткәрү турында» 2019 ел, 22 апрель, 325 нче карары белән расланган «Ел инженеры» республика конкурсын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ел инженеры» республика конкурсын үткәрү турында» 2019 ел, 22 апрель, 325 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 3 август, 642 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Ел инженеры» республика конкурсын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

оештыру комитеты составыннан М.Г.Әхмәтовны, А.Р.Зариповны, Р.А.Кантюковны, Л.Р.Сафинны, И.Э.Фәйзуллинны, А.Ш.Хөсәеновны, С.В.Юшконы чыгарырга;

комитет составына кертергә:

| | |
|---|---|
| Айзатуллин Марат Мансур улын | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрын |
| Җәббаров Марат Азат улын | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары - Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрын |

| | |
|---|---|
| Казаков Юрий Михайловичны | «Казан илкүләм тикшеренү технология университеты» югары белем бирүче федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры, оештыру комитеты рәисе урынбасары вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (килешү буенча) |
| Сәлимгәрәев Айдар Сәетгәрәй улын | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесен |
| Саматов Тимур Илгиз улын | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасарын, оештыру комитеты рәисе урынбасарын |
| Усманов Рөстәм Ринат улын | «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең генераль директорын, оештыру комитеты рәисе урынбасарын (килешү буенча) |
| Хәнифов Фәрит Мөдәррис улын | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрын. |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин